ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

12 05 2021 г. № 476

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 1376 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалар тәрбияләүче гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 27 сентябрендәге 1376 номерлы карарына түбәндәге үзгәре-шләр кертергә:

мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең 1 бүлеге 1.3. пункты 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүнең бер өлешенә өстәмә компенсация билгеләгәндә, аны билгеләү турында гариза бирү ае алдыннан килгән алты календарь ай алдыннан килүче соңгы 12 календарь ай өчен гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып, җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләрнең җан башына уртача керемен исәпләү»;

мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең 2 бүлеге 2.1. пункты 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Аны билгеләү турында гариза бирү ае алдыннан килгән алты календарь ай алдыннан килүче 12 календарь ай өчен гаиләнең һәр әгъзасының керемнәре турында документлар».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Мәгариф идарәсе җитәкчесе Р.М. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов